ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«НАРАТ-ЕЛГИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«НАРАТ-ЕЛГА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРЭМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422980, РТ, Чистопольский район, с.Нарат-Елга ул.Большая 9А, тел.(884342) 3-26-17, E-mail: Nelg.Ctp@tatar.ru

Постановление                                        Карар

№9                                        2019 елның 24 декабре

Чистай муниципаль районының
Нарат-Елга авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон белән, Чистай муниципаль районының «Нарат-Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Чистай муниципаль районының Нарат-Елга авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыеннарында кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Нарат-Елга авылы гражданнар җыенының 2019 елның «14» ноябрендәге 1 номерлы карары нигезендә, Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Чистай муниципаль районының Нарат-Елга авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю буенча тәкъдим ителгән Тәртипне расларга.
2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендлары аша игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында http:/chistopol.tatarstan.ru урнаштырырга.

Нарат-Елга авыл
җирлеге башлыгы                                        А.Р.Хәмитов

Чистай муниципаль районы
Нарат-Елга авыл җирлегенең
Башкарма комитеты тарафыннан
2019 елның 24 декабре 9 номерлы
карары белән расланды

Чистай муниципаль районының
Нарат-Елга авыл җирлеге гражданнарының
үзара салым акчаларын җыю Тәртибе

1. Әлеге Тәртип Чистай муниципаль районының Нарат-Елга авыл җирлеге гражданнарының үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчалары 2020 елның 10 мартына кадәр Чистай муниципаль районының Нарат-Елга авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк, 1 төркем инвалидлардан тыш, 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан, аларның җыенда катнашуларына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә карамастан, түләнә.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) бланкы, Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлеге торак пунктлары территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерү юлы белән яисә имза куеп тапшыру, яки почта элемтәсе аша җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, тулы күләмдә яисә киметелгән күләмдә, аны түләү срогы күрсәтелергә тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акчалар Чистай муниципаль районының «Нарат-Елга авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең шәхси счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләү физик затлар кушуы буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган оешмалар аша, почта күчерүләре (исәп-хисап оешмаларын) Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлеге башкарма комитеты кассасы аша, яисә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталы аша (сылтама буенча), акча күчерү юлы белән башкарыла https://uslugi.tatarstan.ru/.

6. Түләү фактын раслау булып килү касса ордеры, чек-ордер квитанциясе, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Билгеләнгән вакытка кертелмәгән гражданнарның үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләтелә.

ТР Чистай муниципаль<br>районының<br>Нарат-Елга авыл җирлеге<br>гражданнарының үзара салым<br>акчаларын җыю Тәртибенә<br>кушымта

ТР Чистай муниципаль районы Нарат-Елга авыл җирлеге муниципаль берәмлеге бюджетына үзара салым акчаларын бер тапкыр түләү турында

ХӘБӘР (ХӘБӘРНАМӘ) № _______________

Түләүченең Ф. И. атасының исеме
______________________________________________________________________________
Адрес: ________________________________________________________________
____________________________________________________________________ нигезендә
Сезгә, түбәндәге реквизитлар буенча: _________________ срогына кадәр, ___________ суммада, чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр түләү түләргә кирәк.
түбәндәге реквизитлар буенча:_____________________________________________________
Алучы Банк БИК ________________________________________
Сч. № ___________________________________
Алучы Сч. № __________________________________________
ИНН ___________________________________________
КПП ___________________________________________
КБК ________________ ОКАТО ___________________
Түләү билгеләү
______________________________________________________________________________
Җитәкче __________________ __________________________________________
М.П. (имза) (тулы имза)
- - - - - - - - - - - - - - - - - кисү өчен - - - - - - - - - - - - - - -
хәбәр (хәбәрнамә) № _____
_________________ сум күләмендә
Түләүченең Ф. И. атасының исеме ____________________________________________
Адрес: ______________________________________________________________________________
Алды «__» ________________ 20__ ел. ________________________________________
(түләүче имзасы)

Искәрмә. Корешокның өзелгән өлеше _________________авыл җирлеге Башкарма комитетында тутырыла һәм кала.